Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXVII-13**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 29 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 29.12.2021 ел, №XVII-2 карары белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планына (Программасына) үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру максатларында, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 24.07.2017 ел, №XX-20 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы Нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “2022 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт объектының исемлеге һәм сыйфатламасы” 2 Бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 29.12.2021 ел, №XVII-2 карары белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планына (Программасына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

| № п/п | Аталышы | Урнашу урынының адресы | Микъдары (данә), гомуми мәйданы, кв.м. | Функциональ билгеләнеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Автобус FIAT DUCATO, таныклау номеры (VIN)-Z7G244000AS020720, сары төстә. | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп. | 1 данә | М2 категориясендә В класс балаларны йөртү өчен махсус | Ирекле |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Балаларны йөртү өчен транспорт чарасы PEUGEOT BOXER-222335, чыккан елы 2013ел, таныклау номеры (VIN) - XB9222335D0FD1598, сары төстә. | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп. | 1 данә | Балаларны йөртү өчен транспорт чарасы | Иректе |
| 3 | Автобус FIAT DUCATO, чыккан елы 2009 ел таныклау номеры (VIN) - Z7G244000AS011728, сары төстә. | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп. | 1 данә | М2 категориясендә В класс балаларны йөртү өчен махсус | Иректе |
| 4 | Торак булмаган бина - остаханә, диварлары кирпечтән, гомуми мәйданы 112 кв.м., 1973 елда төзелгән 16:34:090101:397<br><br>Җир кишәрлеге 16:34:090101:764 | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Солтан ав., Р. Шәрәфиев ур., 38 йорт<br><br>Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Солтан ав., Р. Шәрәфиев ур., з/у 18 | 112 кв.м.<br><br>1177 кв.м. | Остаханә<br><br>Торак пунктлар җирләре, мәктәпне карап тоту өчен | Иректе |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгы
урынбасары Ф.Г. Әхмәтҗанова